| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ГЛАЗОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ГЛАЗОВО<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның 20 марты № 3

Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Петропавловка торак пунктында гражданнар җыенының 2023 елның 18 ноябрендәге 1нче, 2нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенчагражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы (29.11.2023 №1532 редакциясендә) карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән,Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлеге Петропавловка торак пунктында 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Петропавловка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» карарына һәм 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Глазово торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 1 апреленә 08 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Сез 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Петропавловка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» карарына һәм 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Петропавловка торак пунктында 2024 елда гражданнарның

үзара салымын кертү турында» карарына үзгәреш кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтерү белән килешәсезме:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Үрнәк-Күмәк авылы, Мәктәп урамы, 3а йорт, Глазово авылы, Заречная урамы, 13 йорт, Петропавловка авылы, Горький урамы, 19а йортадресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Глазово авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы

Н.К.Карабаева